КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 980

Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

3. Әлеге карар 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына)

Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин